СОВЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески,
Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Тњбђн Мђтђскђ авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

**Иске Кырлай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**26.01.2016 ел** **№ 14**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2016 елның 22 гыйнварындагы 13 нче номерлы Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты карары нигезендә Иске Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2016 елның 13 мартына Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

«2016 елда Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертү (түләү күләме 100 сум тәшкил иткән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, Бөек Ватан сугышы ветераннары, 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен) 1әм акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - юлларга вак таш салу:<br>Иске Кырлай авылы,<br>ИскеИябаш авылы<br>Өтнә авылы<br>Югары Әзәк авылы | <br>21400 сум<br>20900сум<br>9400сум<br>12700сум |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Түбән Мәтәскә авылы<br>Югары Мәтәскә авылы<br>Мөндеш авылы<br>Казиле авылы | 63000сум<br>37200сум<br>60400сум<br>20100сум |
| 2 | Күмү урыннарын карап тоту | -зират коймаларын урнаштыру һәм карап тоту:<br>Иске Кырлай авылы | 12000сум |
| 3 | Төзекләндерүне оештыру | светильникларны алыштыру һәм урнаштыру:<br>Иске Иябаш авылы<br>Өтнә авылы | 3000сум<br>1000сум |
| | | Барлыгы: | 261100 сум |

Аерым мәсьәләләр буенча экономияләнгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

әйе　　　　　　　　　　　　　　　　　　　юк

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында яисә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Иске Кырлай авылы, Үзәк ур., 12А йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Түбән Мәтәскә авылы, Тукай ур., 2 йорт.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　　　Ф.Г.Сиражетдинов